| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| СОВЕТ НИЖНЕШИТЦИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ШЫТСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| 422067, Республика Татарстан, Сабинский район, с. Нижние Шитцы, ул. Тукая, 15<br>тел. (84362) 46-4-42 | 422067, Татарстан Республикасы, Саба районы, Түбән Шытсу авылы, Тукай урамы, 15 йорт<br>тел. (84362) 46-4-42 |

e-mail: shic.sab@tatar.ru

09.11.2020 № 13

РЕШЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 27 нче апрелендә кабул ителгән 9 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында " гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 27 нче апрелендә кабул ителгән 9 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында " гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 11 498 сум күләмендә расларга.»;

1.2. Карарга 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның гамәлен 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына 2020 елның 1 октябреннән, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, яңа штат расписаниеләрен расларга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

Түбән Шытсу
авыл җирлеге башлыгы: Б.М.Мәүлетов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Советының 2020 елның 9 ноябре, № 13 карарына

Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының акчалата бүләкләре күләме

| Вазыйфалар исемнәре акчалата бүләк күләме (сумнарда) | акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 15759 |
| Депутатлар | 11498 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 11498 |